“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”

# ЧИШМӘ БАШЫ

№ 2
Октябрь
2025 ел

Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча гәҗит

## «Арча 1 нче балалар бакчасы» - "Иң яхшы билингваль балалар бакчасы" республика бәйгесенең икенче этабында

**Татарстан Республикасында «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» грантын алуга конкурста сайлап алуның икенче этабы дәвам итә. 23 нче октябрь көнне комиссия безнең балалар бакчасында булды һәм балаларга билингваль белем бирү өлкәсендә учреждение эшен бәяләде.Балалар бакчасы эшчәнлеген оештыруга якын килүнең системалылыгы, балалар белән эшләү формаларының төрлелеге һәм оригинальлеге, педагоглар һәм балалар эшенең нәтиҗәлелеге, педагогик коллективның методик активлыгы, педагогларның авторлык программалары һәм методик эшләнмәләре булу, шулай ук ата-аналар белән балаларның билингваль белем алу буенча эш формаларының төрлелеге кебек аспектлар бәяләнде. Комиссия балалар бакчасының билингваль белем бирү өлкәсендәге уңышлы эшен билгеләп үтте.**









## БАКЧА БЕЛӘН КИТАПХАНӘ БЕРДӘМЛЕГЕ

**29 нчы октябрь көнне бакчабызда балалар язучысы Җ. Дәрзаманның тууына 80 ел тулуга багышланган «Балачак дөньясы» дип аталган искә алу кичәсе булып узды. Балалар язучының шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйләделәр, җырлар җырладылар, татар халык биюләрен башкардылар. Бакчабызга Арча Үзәк балалар китапханәсе хезмәткәрләре – Гөлназ Рамилевна кунакка килде. Ул балаларның җитез, үткен телле булуларын ассызыклады. Киләчәктә уңышлар теләп, район китапханәсеннән рәхмәт хаты белән бүләкләде. Арча үзәк китапханәсе белән хезмәттәшлегебез дәвамлы булыр дип ышанасы килә.**






## АРЧА «1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» АЛДЫНГЫЛАР ХӘРӘКӘТЕНДӘ





Беренчеләрнең хәрәкәте-балалар, ата-аналар, педагоглар һәм тәрбиячеләр диалогы өчен өстәмә мөмкинлек. Биредә һәркем үз идеяләрен һәм хыялларын тормышка ашыра ала. Хәрәкәт чаралары һәр катнашучының потенциалын ача, көн саен үзеңнең иң яхшы версиянә әверелергә ярдәм итә. Беренчеләрнең хәрәкәте-шәхесне тәрбияләү һәм үстерүнең уникаль программасы. Актив һәм җаваплы яшьләр үстерүдә ярдәмче. Безнең бакчаның мәктәпкә әзерлек төркеме балалары да Беренчеләр хәрәкәте белән танышалар, махсус дәфтәрдә эшләргә өйрәнәләр.

## ТАТАРЧА ОЛИМПИАДА

Бакчабызда “Татарча өйрәнәм” дип аталган татарча олимпиаданың сайлап алу туры үтте. Анда мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалар татар теленнән алган белемнәре белән куч сынашты. Балалар мөстәкыйль рәвештә төрле биремнәр башкардылар. Иң күп балл җыйган ике бала ноябрь аенда олимпиаданың муниципаль турында көч сынашачак. Аларга уңышлар телибез.





## УЙНЫЙ_УЙНЫЙ ӨЙРӘНӘБЕЗ

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы шартларында «Актив стена» технологиясенең асылы шунда: тәкъдим ителгән иллюстратив, дидактик материалны кулланып, бала үзенең мөстәкыйль эшчәнлеген планлаштыра ала. Моның өчен стеналарда сюжет сурәтләнә, кесәләр, келәм тукыма, магнит киштәләр, тасмалар, тематик рәсемнәр беркетелә. Без дә төркемнәрдә актив стеналар булдырдык. Алар ярдәмендә балаларның сөйләм теле камилләшә, бәйләнешле сөйләме формалаша, фантазиясе арта.




